РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ АДАВ-
ТУЛУМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АДАВ-ТОЛЫМБАЙ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2017 ел. № 1-28

«Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл
итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигездә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарына (алга таба «Районның җирле үзидарә органнары») тәкъдим итәргә, Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең (алга таба «Җирлек») Буа муниципаль районы составына керүче торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү вәкаләтләрен үз карамагына алырга.

2. Буа муниципаль районы Советы белән 1 нче кушымта нигезендә әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Бу карарны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге башкарма комитетына «2017 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында»Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы карары проектын эшләп чыгарырга һәм карауга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар имзаланганнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән янгын куркынычсызлыгы беренчел чараларын тәэмин итү өлкәсендәге хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Адав-Толымбай
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Хөсниева

«Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Адав-Толымбай авыл Советының
2017 елның 21 мартындагы
1-28 номерлы карарына кушымта

Буа муниципаль район Советына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешү

Буа шәһәре «__»_______ 2017 ел.

Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы, алга таба "Җирлек советы" дип аталачак, Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы Хөсниева Айгөл Фәрит кызы, Устав нигезендә эш итүче, бер яктан, Буа муниципаль районы Советы һәм Буа муниципаль районы Советы исеменнән Устав нигезендә эш итүче, Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары Еремеев Илдар Фәрид улы , икенче яктан, "Яклар" дип аталган, түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.2. Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек советына Буа муниципаль районы составына керүче Адав-Толымбай авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү вәкаләтләренең бер өлешен район советына тапшыру тора.

2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Җирлек Советы Район Советына тәкъдим итәргә тиеш:
Әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары (алга таба-вәкаләтләр).
2.2. Җирлек Советы хокуклы:
район Советы тарафыннан вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук бирелгән финанс чараларның әлеге Килешүнең 5.1 пунктларда билгеләнгән тәртиптә максатчан файдалануын тикшереп торырга.
әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүматны район Советыннан алырга.
2.3. Район Советы бурычлы:
вәкаләтләрне закон таләпләре нигезендә башкару, шул исәптән җирлек Советы тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны тәэмин итүгә;
җирлек Советына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисаплар, шулай ук аерым запрослар буенча килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат тапшырырга.
2.4. Район Советы түбәндәгеләргә хокуклы:
Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек Советы тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алу һәм файдалану;
вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалану каралган.

3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.
3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме елына _______ сум күләмендә билгеләнә.
3.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары бер тапкыр

күчерелә.

3.4. Район Советы финанс чараларын максатчан кулланмаган очракта, алар җирлек советы таләбе буенча, максатчан файдаланылмау ачыкланган көннән ун көн эчендә җирлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

4.1. Җирлек советы вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында район Советыннан кирәкле мәгълүматны сорый. Район Советы җирлек Советы соравы буенча сорала торган мәгълүматны тәкъдим итәргә һәм аның вәкилләренең тикшерелә торган объектларга үтемлелеген тәэмин итәргә тиеш.

4.2. Хисаплар формасы һәм аларны бирү тәртибе җирлек советының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Тапшырылган финанс чараларын тотуны Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге Советы контрольдә тота.

## 5. Килешү вакыты

5.1. Әлеге Килешү бер елга төзелгән, ул имзаланганнан соң үз көченә керә һәм 2017 елның «31» декабренә кадәр гамәлдә. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы 2017 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән янгын куркынычсызлыгы беренчел чараларын тәэмин итү өлкәсендәге хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

5.2. Әлеге Килешү бер календарь елына озайтылган дип санала, әгәр Якларның берсе дә аны юкка чыгару турында Килешүнең 5.1 пунктында каралган срокка ике ай кала хәбәр итмәсә.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе.

6.1. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

бер яклы тәртиптә, бер Яның үз бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта.

6.2. Әлеге Килешүне юкка чыгару турында белдерү икенче Якка, аның гамәлдә булу датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район Советы җирлек Советына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган кулланылмаган финанс чараларын кире кайтара.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен килешү яклар тарафыннан үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык җитү нигезе булып тора.

7.2. Әлеге килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле Як икенче Якка 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3 Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне киләчәктә үтәүдән азат итми.

## 8. Бәхәсләрне чишү тәртибе

Әлеге килешүне үтәү белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл ителә.

Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итә алмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Әлеге килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара килешүе буенча кертелә һәм өстәмә килешү белән язмача рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр бу килешүнең

аерылгысыз өлеше.

9.4. Әлеге Килешү ике якның һәрберсе өчен берәр юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде.

10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары<br><br>_________________/И.Ф. Еремеев/<br>М.У. | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы<br><br>__________________/А.Ф. Хөсниева/<br>М.У. |